**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Саба районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Саба районының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

Килдебәк авылындагы Кооператив урамы;

Югары Симет авылындагы Комсомол урамы.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны иткә сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән

территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 20 май
№ ПУ-468